# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 24 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында" 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I өлеш); 2009, № 2; № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкаләтләре**

Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе максатларында хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы:

Татарстан Республикасы территориясендә хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен һәм хезмәт шартларын яхшыртуның һәм хезмәтне саклауның федераль максатчан программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

хезмәт шартларын яхшыртуның һәм хезмәтне саклауның республика максатчан программаларын әзерли, аларны гамәлгә ашыруны һәм аларның үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итә;

Татарстан Республикасы территориясендә хезмәткәрләрне, шул исәптән оешмалар җитәкчеләрен, шулай ук эш бирүчеләрне – индивидуаль эшкуарларны хезмәтне саклау буенча билгеләнгән тәртиптә укыту үткәрүне, аларның хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерү үткәрүне, шулай ук производствода зыян күргәннәргә беренче ярдәм күрсәтү буенча укыту, хезмәтне саклау буенча инструктаж, эш урынында стажировка үткәрүне оештыра;

Татарстан Республикасы территориясендә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра, хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрүне һәм хезмәтне саклау эшләрен оештыруның хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләренә туры килүен раслауны үткәрүне оештыра;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы эш бирүчеләрдә хезмәт шартлары һәм аны саклау торышы турындагы мәгълүмат җыюны һәм эшкәртүне оештыра;

хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнары вәкаләтләренә кертелмәгән бүтән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары нигезендә үти.";

2) 10 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"үз ведомствосындагы оешмаларда эшчәнлекнең төп юнәлешләрен билгели һәм дәүләт сәясәтен һәм хезмәт законнарын гамәлгә ашыру буенча чаралар күрә;";

3) IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"IV бүлек

**ХЕЗМӘТ ЗАКОННАРЫНЫҢ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ХОКУКЫ НОРМАЛАРЫ БУЛГАН БҮТӘН НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРНЫҢ ҮТӘЛЕШЕНӘ КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ ТИКШЕРЕП ТОРУ**";

4) 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"22 статья. **Хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары булган бүтән норматив хокукый актларның үтәлешенә дәүләт күзәтчелеге һәм тикшереп торуы**

Татарстан Республикасы территориясендә хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары булган бүтән норматив хокукый актларның үтәлешенә дәүләт күзәтчелеге һәм тикшереп торуы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 15 марты
№ 3-ТРЗ